| МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.04.2026 Казан шәһәре № 72-ОД

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2025 елның 29 июлендәге 132-ОД номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүне һәм сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануына карата таләпләр үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының 2025 елның 29 июлендәге 132-ОД номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы территориясе чикләрендә урнашкан сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануын тәэмин итүне һәм сәүдә объектларының (территорияләренең) террорчылыктан саклануына карата таләпләр үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәреш кертеп, 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«3. Контрольлек нәтиҗәсенә тасвирлама**

3.1. Тикшерү үткәрү нәтиҗәләре буенча Министрлык тарафыннан ачыкланган хокук бозулар булу-булмавы турында белешмәләр булган тикшерү акты рәсмиләштерелә.

3.2. Тикшерү нәтиҗәләре буенча ачыкланган һәм тикшерү актында чагылдырылган хокук бозулар (шул исәптән Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Россия Федераль иминлек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан элегрәк билгеләнгән искәрмәләрне үтәмәү буенча ачыкланган

хокук бозулар) фактларына карата тикшерү материаллары Министрлык тарафыннан, алга таба эшләү өчен, әлеге вәкаләтле органнарга җибәрелә.»

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр О.В.Коробченко